| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МАЛОЛЫЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

« 29 » июнь 2026 г.

КАРАР

№ 28

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының
Кече Лызи авыл җирлеге гражданнарын беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы 08.12.2016 елгы №17 нче номерлы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Балтач районы прокуратурасының 25.05.2026 №02-08-01-2026/Прдп 173-26-20920011 протесты нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитетының 08.12.2016 №17 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге гражданнарын беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәгә (13.06.2023 № 42 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.8 пунктны төшереп калдырырга;

1.2. 3.7 пунктта «2 атна эчендә» сүзләрен «10 эш көне дәвамында» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.11 пунктта «тапшырырга» сүзеннән соң «электрон формада ачыкланган көннән алып 10 эш көне эчендә, шул исәптән алына торган машина мәгълүмат саклагычында» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитетының 08.12.2016 № 17 карары белән (13.06.2023 №42 үзгәрешләр белән) расланган Кече Лызи авыл җирлегендә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хезмәткәрнең функциональ бурычларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләрне җыюны, саклауны һәм эшкәртүне оештыру һәм тәэмин итү максатларында хәрби-исәпкә алу хезмәткәре:

а) запаста торучы һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле, яшәү яисә булу (3 айдан артык срокка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча теркәлмәгән, үз территорияләрендә яшәүче гражданнарны һәм гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыра;

б) үз территорияләрендә яшәүче яисә булучы (3 айдан артык вакытка), шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча теркәлмәгән һәм хәрби исәпкә куелырга тиешле гражданнарны эчке эшләр органнары белән берлектә ачыклый;

в) үз территорияләрендәге оешмаларның исәбен алып бара һәм аларда хәрби исәп алып баруны тикшереп тора;

г) беренчел хәрби исәпкә алу документларын машинкада һәм электрон төрләрдә Россия Федерациясе Оборона министрлыгы билгели торган тәртиптә һәм рәвешләр буенча алып бара һәм саклый.

2. Беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләрне актуаль хәлдә тоту һәм хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләрне актуаль хәлдә тотуны тәэмин итү максатларында хәрби-исәпкә алу хезмәткәре:

а) беренчел хәрби исәпкә алу документларын тиешле хәрби комиссариатларның һәм оешмаларның хәрби исәпкә алу документлары белән елга кимендә 1 мәртәбә чагыштыра;

б) беренчел хәрби исәпкә алу документларындагы белешмәләргә үз вакытында үзгәрешләр кертә һәм 10 эш көне эчендә хәрби комиссариатларга кертелгән үзгәрешләр турында Россия Федерациясе Оборона министрлыгы билгели торган форма буенча хәбәр итә;

в) оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация буенча Россия Федерациясе законнарында һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән бурычларын аңлата, аларның үтәлешен тикшереп тора, шулай ук күрсәтелгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылык турында хәбәр итә;

г) оешмаларның вазыйфаи затлары һәм гражданнарның хәрби исәпкә алу, мобилизацион әзерлек һәм мобилизация бурычларын үтәмәү очраклары турында белешмәләрне алар ачыкланган көннән алып 10 эш көне эчендә электрон формада, шул исәптән мәгълүматны машинада алына торган саклагычта тапшыра.

3. Гражданнарны хәрби исәпкә куюны оештыру һәм тәэмин итү максатларында хәрби-исәпкә алу хезмәткәре:

а) хәрби билетларның (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыкларның), хәрби билетлар яисә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар таныклыклары урынына белешмәләрнең, шул исәптән электрон документ рәвешендә, булуын һәм дөреслеген, шулай ук алардагы язмаларның дөреслеген, мобилизация күрсәтмәләренең (хәрби бурычлыларга хәрби билетларда яисә хәрби билетлар урынына белешмәләрдә аларны тапшыру турында тамгалар булганда) булуын тикшерә, шәхси электрон карталар (хәрби исәпкә алу документларында аларны бирү турында тамгалар булганда), гражданнарны элеккеге яшәү урыны буенча хәрби исәптән төшерү турында хәрби исәпкә алу документларында тамгалар, Россия Федерациясе гражданнары паспортларында аларның хәрби бурычка мөнәсәбәте турында тамгалар, Россия Федерациясе Кораллы көчләренең шәхси номерлары белән жетоннар (хәрби бурычлылар өчен хәрби билетларда аларны тапшыру турында тамгалар булганда)булуын тикшерә;

б) запастагы офицерларга беренчел исәп карточкаларын тутыра. Прапорщиклар, мичманнар, старшиналар, сержантлар, солдатлар һәм запастагы матросларның алфавит карточкаларын һәм исәп карточкаларын (2 нөсхәдә)

тутыра. Призывникларны беренчел хәрби исәпкә алу карталарын тутыралар. Күрсәтелгән документлар хәрби билетлардагы (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыкларда), хәрби билетлар урынына белешмәләрдә һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар таныклыкларындагы язмалар нигезендә, шул исәптән электрон документ рәвешендә тутырыла. Шул чакта гражданнарның гаилә хәле, белеме, эш (уку) урыны, вазыйфасы, яшәү урыны яки булу урыны турында, шул исәптән яшәү урыны һәм (яисә) булу урыны буенча теркәлү белән расланмаган белешмәләр һәм хәрби исәпкә алына торган гражданнарның документларындагы башка кирәкле белешмәләр төгәлләштерелә.;

в) хәрби билетларны (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыкларны), хәрби билетлар урынына белешмәләрне, шәхси электрон карталарны, прапорщикларның, мичманнарның, старшиналарның, сержантларның, запастагы солдатларның һәм матросларның алфавит һәм исәп карточкаларын, хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнарның таныклыкларын, шул исәптән электрон документ рәвешендә, призывникларны беренчел хәрби исәпкә алу карталарын, шулай ук гражданнарның хәрби бурычка мөнәсәбәте турында тамгалары булмаган Россия Федерациясе гражданнары паспортларын 2 атна эчендә хәрби учетка куелуны рәсмиләштерү өчен хәрби комиссариатларга тапшыра. Хәрби исәпкә кую өчен тиешле хәрби комиссариатка шәхси килү кирәклеге турында призывникларга хәбәр итә. Моннан тыш, хәрби комиссариатларга гражданнарның хәрби исәп документларында һәм мобилизацион күрсәтмәләрендә табылган төзәтмәләр, төгәлсезлекләр, ялган битләр һәм тулы булмаган күләмдә битләр турында хәбәр итә. Гражданнарны хәрби исәпкә куюны алар тапшырган хәрби исәпкә алу документлары нигезендә рәсмиләштерү мөмкин булмаган очракта, хәрби-исәпкә алу хезмәткәре гражданнарга хәрби комиссариатларга шәхсән килү кирәклеге яисә кирәкле белешмәләрне хәрби комиссариатка электрон рәвештә җибәрү турында хәбәр итә. Гражданнар тарафыннан хәрби исәпкә кую өчен кирәкле белешмәләрне электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан файдаланып җибәрү гамәлгә ашырыла. Гражданнардан хәрби исәпкә алу документларын кабул иткәндә распискалар бирелә.

4. Гражданнарны хәрби исәптән төшерүне оештыру һәм тәэмин итү максатларында хәрби-исәпкә алу хезмәткәре:

а) күрсәтелгән документларны тиешенчә рәсмиләштерү өчен гражданнарның хәрби бурычка мөнәсәбәте турында тамгалар булмаган очракта, хәрби комиссариатларга хәрби исәпкә алу документларын һәм паспорт тапшыра. Запастагы офицерларга һәм призывникларга хәрби учеттан төшү өчен тиешле хәрби комиссариатка шәхси килү кирәклеге турында хәбәр итә. Муниципаль берәмлектән читкә китүче хәрби бурычлылардан муниципаль берәмлекләрнең хәрби комиссарлары карарлары белән мобилизация күрсәтмәләре алынырга мөмкин, бу хакта хәрби билетларда (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыкларда) яисә хәрби билетлар урынына белешмәләрдә тиешле тамга ясала. Хәрби бурычлыларның хәрби-исәпкә алу мәгълүматларын төгәлләштерү кирәк булган очракта аларга хәрби комиссариатларга шәхси килү кирәклеге турында хәбәр итәләр. Гражданнардан хәрби исәп документларын һәм паспортларны кабул иткәндә распискалар бирелә;

б) беренчел хәрби исәпкә алу документларында хәрби исәптән төшерү турында тиешле тамгалар ясый;

в) хәрби исәптән төшермичә муниципаль берәмлектән читтә яңа яшәү урынына киткән гражданнар исемлеген 2 атна эчендә төзи һәм хәрби комиссариатларга тапшыра;

г) хәрби учеттан төшерелгән гражданнарның беренчел хәрби исәпкә алу документларын хәрби комиссариатның исәп белешмәләре белән чираттагы чагыштыруга кадәр саклый, шуннан соң аларны билгеләнгән тәртиптә юкка чыгара.

5. Хәрби-исәпкә алу хезмәткәре 1 февральгә кадәр хәрби комиссариатка (Татарстан Республикасы Балтач районы, муниципаль) алдагы елда беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисаплар тапшыра.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы Л.М.Михайлова